ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

18 01 2021 г. № 13

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 733 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 733 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның исемендә «эскиз проектын килештерү» сүзеннән соң «(гамәлдән чыгару)» сүзен өстәргә;

карарның 1 пунктында «эскиз проектын килештерү» сүзеннән соң «(гамәлдән чыгару)» сүзен өстәргә;

карарга кушымтада:

кушымта исемендә «эскиз проектын килештерү» сүзеннән соң «(гамәлдән чыгару)» сүзен өстәргә;

1.1. пунктында «килештерү» сүзеннән соң «(гамәлдән чыгару)» сүзен өстәргә;

1.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Әлеге Регламентны куллану максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Түбән Кама шәһәр Советының 2013 елның 30 гыйнварындагы

48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен тышкы төзекләндерү һәм санитар карап тоту кагыйдәләрендә каралган төшенчәләр һәм терминнар кулланыла.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны астында әлеге Регламентта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районы шәһәр яки авыл җирлегендә (шәһәр округында) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы) аңлашыла.

Техник хата астында әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуныңише хата) аңлашыла.»;

1.6. пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» кушымтасының 2 бүлеген яңа теркәлгән редакциядә бәян итәргә;

3.1.1. пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) тышкы мәгълүмат чараларын (паспортларын) урнаштыру эскиз проектын килештерү (гамәлдән чыгару) турында карар кабул итү;»;

3.1.2. пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3.2. пунктының өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә һәм урнаштыруны куллануны тәкъдим итә» сүзләрен «урнаштыру кирәклеген» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, яисә ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.6. пункты нигезендә Бүлеккә документлар тапшыра.

Гаризалар кабул итүне алып баручы Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә буенча эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.6. пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозулар, өстәүләр, сызып ташланган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмау).

Кисәтүләр булмаган очракта Бүлек белгече башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында билге белән тапшырылган документларның исемлеге күчермәләрен тапшыру.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларга карата кисәтүләр булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы Бүлек хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүче документларны кабул итүне таләп иткән очракта, Бүлек хезмәткәре башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында билге белән тапшырылган документларның исемлеге күчермәләрен тапшыру.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар 15 минут эчендә кабул ителә;

гаризаны теркәү гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.»;

3.4.1. пунктында бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- тышкы мәгълүмат чараларын кушу күздә тотылган күчемсез милеккә хокуклар турында мәгълүматлар»;

3.5. пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортларны) урнаштыру эскиз проектын килештерү (гамәлдән чыгару) турында карар кабул итү.»;

3.5.1. пунктының дүртенче абзацында «эскиз проектын килештерү» сүзеннән соң «(гамәлдән чыгару)» сүзен өстәргә;

3.5.1. пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече документларны комиссия каравына җибәрүне башкара»;

3.5.1. пунктының җиденче абзацында «урнаштыру өчен» сүзләреннән соң «урнаштыру өчен эскиз проектын гамәлдән чыгару)» сүзләрен өстәргә;

3.5.2. пунктында «каралырга мөмкин» сүзләрен «карала» сүзенә алмаштырырга;

3.6.1. пунктының беренче һәм өченче абзацларында, 3.6.2 пунктының беренче абзацында «эскиз проекты» сүзләреннән соң «(эскиз проектын гамәлдән чыгару турында карар)» сүзләрен өстәргә;

3.6.2. пунктының өченче абзацында. 3.7 пунктының икенче һәм бишенче абзацларында «(паспорт)» сүзеннән соң «(эскиз проектын гамәлдән чыгару турында карар)» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 4 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

Регламентка 5 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

Регламентның «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аның үтәлешен контрольдә тотуны

гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары реквизитлары» 5 нчы кушымтасын 6 нчы кушымта дип санарга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 18 нче гыйнвар
13 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге |
|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы | Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проектын килештерү (гамәлдән чыгару) |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органы атамасы | Башкарма комитет |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | 1. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру өчен эскиз проектын килештерү яисә килештерүдән баш тарту.<br>2. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру өчен эскиз проектын гамәлдән чыгару яисә гамәлдән чыгарудан баш тарту |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза биргәннән соң 30 календарь көн |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон), (РФ законнары җыелмасы, 06.10.2003, № 40, 3822 ст.);<br>2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) («Российская газета», № 95, 05.05.2006); |

| | |
|---|---|
| | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);<br>«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 октябрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 419-ФЗ номерлы Федераль закон) («Российская газета», № 278, 05.12.2014);<br>«Куллanучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Федераль закон (алга таба – 2300-1 номерлы Федераль закон) («РФ законнары җыелмасы», 15.01.1996, № 3, 140 ст.);<br>«Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Советская Татария», № 146-147, 25.07.1992);<br>«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 16-ТРЗ номерлы ТР Законы) («Татарстан Республикасы», № 111, 02.08.2014);<br>«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, 155-156 номерлары, 03.08.2004);<br>Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен тышкы төзекләндерү һәм санитар тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы 48 номерлы карары (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре).<br>Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);<br>Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге |

| | |
|---|---|
| | 1491 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары (алга таба – Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 1491 номерлы карары) |
| 2.6. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тәкъдим ителергә тиеш булган документларга бүлеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга эскиз проектын килештерү өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырыла:<br>1. Регламентка 1 нче кушымта нигезендә, нөсхәләр санын күрсәтеп, гаризага кушып бирелә торган документларның исемлеген теркәп тутырылган муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза;<br>2. Шәхесне раслаучы документ;<br>3. Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) - төп нөсхә күрсәткәндә күчермәсе (тәкъдим ителгән форма Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән).<br>4. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган биләгән бинага, урынга, капиталь булмаган объектка мөрәҗәгать итүченең милек хокукын раслаучы хокук билгели торган документларның күчермәләре (күчемсез милек объектларына дәүләт теркәве үткәрелмәгән очракта бирелә).<br>5. Аерым тора торган тышкы реклама чарасын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган бина, стационар булмаган объект урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукын раслаучы (билгеләүче) хокук билгеләүче документлар күчермәләре, әгәр җир кишәрлегенә хокук Россия Федерациясе законнары нигезендә аның күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип таныла икән (күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләр булмаган очракта тапшырыла) (стационар булмаган сәүдә объектларында урнаштырыла торган аерым тора торган тышкы мәгълүмат чараларын килештерү өчен).<br>6. Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проекты, Татар- |

| | |
|---|---|
| | стан Республикасының ике дәүләт теле турындагы законнар таләпләрен үтәп, Регламентка 3 нче кушымта нигезендә, ике нөсхәдә (эскиз проектында ике яктан бастырылган һәр тышкы мәгълүмат чарасына аерым).<br>7. тиешле күчемсез милек милекчесе яисә башка законлы хуҗасының, әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез милекнең милекчесе яки бүтән законлы хуҗасы булмаса, бу мөлкәткә тышкы мәгълүмат чараларын кушуга ризалыгын язма рәвештә раслау (тәкъдим ителә торган форма Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән).<br>8. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортларны) бер адрес буенча урнаштыру буенча эскиз проектларын килештерү турында икедән артык гариза бирелгән очракта, килештерүгә бирелгән тышкы мәгълүмат чараларының кәгазьдә А4 форматында төсле фотосурәтләрен тапшырырга кирәк.<br>Элек әлеге конструкциягә килешү алган конструкция милекчесе тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыруга эскиз проектын гамәлдән чыгару өчен тапшырыла:<br>1. Килешүне гамәлдән чыгару турында гариза (Регламентка 5 нче кушымта).<br>2. Шәхесне раслаучы документ.<br>3. Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) - төп нөсхә күрсәткәндә күчермәсе (тәкъдим ителгән форма Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән).<br>Әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез милекнең милекчесе яки бүтән законлы хуҗасы булмаса, тышкы мәгълүмат чарасы кушылган тиешле күчемсез милекнең милекчесе яки бүтән законлы хуҗасы белән килешүне гамәлдән чыгару өчен тапшырыла:<br>1. Килешүне гамәлдән чыгару турында гариза (Регламентка 5 нче кушымта).<br>2. Шәхесне раслаучы документ.<br>3. Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) - төп нөсхә күрсәткәндә күчермәсе (тәкъдим ителгән форма Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән). |

| | |
|---|---|
| | 4. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган биләгән бинага, урынга, капиталь булмаган объектка мөрәҗәгать итүченең милек хокукын раслаучы хокук билгели торган документларның күчермәләре (күчемсез милек объектларына дәүләт теркәве үткәрелмәгән очракта бирелә).<br>5. Аерым тора торган тышкы реклама чарасын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган бина, стационар булмаган объект урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукын раслаучы (билгеләүче) хокук билгеләүче документлар күчермәләре, әгәр җир кишәрлегенә хокук Россия Федерациясе законнары нигезендә аның күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танызла икән (күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләр булмаган очракта тапшырыла) (стационар булмаган сәүдә объектларында урнаштырыла торган аерым тора торган тышкы мәгълүмат чараларын килештерү өчен).<br>Барлык материаллар да кәгазьдә, шулай ук jpg форматында электрон рәвештә бирелә.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (юридик затлар өчен) өземтә;<br>2. Шәхси эшмәкәрләрнең (шәхси эшмәкәрләр өчен) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган биләгән бинага, урынга мөрәҗәгать итүченең теркәлгән хокукын раслаучы документ (әгәр мондый документ дәүләт теркәве узарга тиеш булса).<br>4. Аерым тора торган тышкы реклама чарасын урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны (эшчәнлек алып бару урыны) булган бина урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукын раслаучы (билгеләүче) хокук билгеләүче документлар (күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләр булган очракта);<br>5. Тышкы мәгълүмат чараларын кушу күздә тотылган күчемсез милеккә хокуклар турында белешмәләр; |

| | |
|---|---|
| | 6. Бинаны арендалау килешүе - муниципаль милектәге бинаны арендалау шартнамәсе төзелгән очракта. |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проектын килештерү буенча хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1) тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>2) гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген бертөсле аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар бар;<br>3) тиешле булмаган органга документлар тапшыру;<br>4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>5) Башкарма комитетта соралган мәгълүматларның булмавы;<br>6) тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) һәм аның территориаль урнаштыру өчен эскиз проектының транспорт хәрәкәте куркынычсызлыгы турында норматив актлар таләпләренә туры килмәве;<br>7) тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проектының төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләргә, шул исәптән ике дәүләт теле турындагы законнарны үтәү таләбенә туры килмәве;<br>8) тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проектының биналар фасадларына тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясенә туры килмәве.<br>9) эскиз проекты тәкъдим ителгән конструкция (паспорт) тышкы мәгълүмат чараларының билгеләренә туры килми;<br>10) тышкы мәгълүмат чараларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең эшчәнлек төре гамәлдәге законнарга каршы килә (тәмәке төтене йогынтысына, ломбардлар эшчәнлегендәге |

| | |
|---|---|
| | чикләүләргә, алкогольле продукцияне сатуга бәйле закон таләпләренә);<br>11) фасадның мәгълүмати конструкциясен урнаштыру өчен күздә тотылган җир кишәрлегендә тышкы реклама яки мәгълүмат чарасы урнаштырылган, урнаштыру өчен рөхсәт (килештерү) вакыты чыкмаган яисә мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көннән соң килә торган 30 көн эчендә чыга.<br>Конструкция милекчесе тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру эскиз проектын гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда булган дөрес булмаган мәгълүматны ачыклау;<br>2) тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>3) мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытка мәгълүмат конструкциясе гаризасында күрсәтелгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруны килештерү вакыты чыккан;<br>4) мөрәҗәгать итүченең паспортны гамәлдән чыгару буенча эшләрне туктату турында гариза белән мөрәҗәгате.<br>Тышкы мәгълүмат чарасы кушылган әлеге күчемсез милекнең милекчесе яки башка законлы хуҗасы тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыруның эскиз проектын (паспортын) гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр, әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез милекчесе яки башка законлы хуҗасы булмаса:<br>1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда булган дөрес булмаган мәгълүматны ачыклау;<br>2) тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>3) мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытка мәгълүмат конструкциясе гаризасында күрсәтелгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруны килештерү вакыты чыккан;<br>4) мөрәҗәгать итүченең паспортны гамәлдән чыгару буенча эшләрне туктату турында гариза белән мөрәҗәгате. |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә |

| | |
|---|---|
| итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны федераль законнарда, алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган очракларда аны алу ысуллары | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Чират булганда, муниципаль хезмәт алуга гариза бирү 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соратуын теркәү срогы | Документлар тапшырганнан соң 15 минут эчендә. |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату тутыру урыннарына, һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле тутыру үрнәкләре һәм документлар исемлеге булган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен |

| | |
|---|---|
| булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр | исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында һәркем өчен мөмкин булган формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм, шул исәптән аны алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү, башка кирәкле гамәлләр кылу, шулай ук инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда бүтән ярдәм күрсәтү тәэмин ителә. |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән һәркем файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге Башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан |

| | |
|---|---|
| | Башкарма комитетта алынырга мөмкин. |
| 2.14 Башка таләпләр, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннары аша муниципаль хезмәт күрсәтү башкарылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы соратып алу составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.<br>Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Бүлектә алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә |

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 18 нче гыйнвар
13 номерлы карарына
2 нче кушымта

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын)
урнаштыру проектын килештерү буенча
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

БЕЛЕШМӘ

(Тышкы мәгълүмат чарасы кушылган җир кишәрлеге, бина яки башка күчемсез милек хуҗасы ФИӘ), тышкы мәгълүмат чараларын карау буенча комиссиядә килештерелгән дизайн-проект нигезендә, 5 ел срокка, ________________________________________адресы буенча урнашкан бина фасадында «Исеме» утлы мәгълүмат элмә тактасын кую һәм урнаштыруга (Тышкы мәгълүмат чарасы хуҗасы ФИӘ) үз ризалыгын бирә.

| |
|---|
| Җирлеккә бәйле фото |

_______________________/_______________________/
имза (ФИӘ)

мөһер (булса)

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 18 нче гыйнвар
13 нче номерлы карарына
3 нче кушымта

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын)
урнаштыру проектын килештерү буенча
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Теркәү номеры _____
«___» ______________ 20___ел

Мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру өчен эскиз проектын гамәлдән чыгаруга гариза

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Тышкы мәгълүмат чарасы хуҗасы турында мәгълүмат | |
| 1.1 | Оешма (шәхси эшмәкәр) исеме | |
| 1.2 | Юридик адрес | |
| 1.3 | Дәүләт теркәвенә алу турында таныклык датасы һәм номеры | |
| 1.4 | Салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН) | |
| 1.5 | Җитәкченең Ф.И.Ә. | |
| 1.5.1 | Телефон /факс | |
| 1.5.2 | E-mail | |
| 2 | Тышкы мәгълүмат чарасы кушыла торган җир кишәрлеге, бина яки башка күчемсез милекнең милекчесе турында белешмәләр | |
| 2.1 | Оешма (шәхси эшмәкәр) исеме | |
| 2.2 | Күчемсез мөлкәтнең кадастр номеры | |
| 3 | Урнаштырыла торган тышкы мәгълүмат чаралары турында мәгълүмат | |
| 3.1 | Урнашу урыны (урнашу адресы) | |
| 3.2 | Тышкы мәгълүмат чарасы төре | |
| 3.3 | Мәгълүмати кыр мәйданы | |
| 3.4 | Төнге яктырткыч булу | |
| 4 | Документлар килештерүне гамәлгә ашыручы ышанычлы зат (фирма) турында белешмәләр | |
| 4.1 | Ф.И.Ә. (фирма исеме) | |
| 4.1.1 | Телефон/факс | |
| 4.1.2 | E-mail | |
| 5 | Тапшырыла торган документлар исемлеге: | |
| 5.1 | | |
| 5.2 | | |

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты: гариза бирү көнен дә кертеп, 30 көн (59-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы)

Түбән Кама муниципаль районында тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү регламенты белән таныштым:

______________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче имзасы)

Бирелгән белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:

________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче имзасы)

Гариза тапшыру датасы: «____»_____________________ ел

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 18 нче гыйнвар
13 нче номерлы карарына
4 нче кушымта

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортын)
урнаштыру проектын килештерү буенча
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | 42-46-49 | zaminvest.nk@tatar.ru |
| Тышкы реклама белән эшләү бүлеге җитәкчесе | 43-15-35 | Ruzilya.Urmancheva@tatar.ru |
| Тышкы реклама белән эшләү бүлеге белгече | 42-40-10 | reklama.nmr@yandex.ru |